СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 14 декабре № 23/9

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының депутатларга, сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары, Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы (2018 елның 11 маендагы 27/3, 28.09.2020 № 1/5, 03.02.2022 № 16/1, 10.11.2022 № 22/3 редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **1 пунктта** «11 958» саннарын «12 688» саннарына алмаштырырга;

2) **1 нче Кушымта таблицасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ ДАИМИ НИГЕЗДӘ БИЛӘҮЧЕ ЗАТЛАРГА, КОНТРОЛЬ-ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНӘ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ ҺӘМ ШАРТЛАРЫ**

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 төркем | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Муниципаль район Башлыгы | 33 592,00 | | | |
| Чүпрәле муниципаль районы башлыгы урынбасары | 30 233,00 | | | |
| Контроль-хисап органы рәисе | 30 233,00 | | | |
| Авыл җирлеге башлыгы урынбасары | | 15 414,00 | | |
| Авыл җирлеге Башлыгы | | | | 17 390,00»; |

3) **2 нче Кушымта** таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ**

| Вазыйфаның атамасы | Вазыйфаи эш хакы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 32 989,00 |
| Район Советы аппараты җитәкчесе | 29 944,00 |
| Район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары | 29 690,00 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 29 563,00 |
| Эшләр идарәчесе | 27 787,00 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 27 153,00 |
| Бүлек башлыгы | 23 093,00 |
| Район Башлыгы киңәшчесе | 20 174,00 |
| Район Башлыгы ярдәмчесе | 20 174,00 |
| Район Башкарма комитеты Җитәкчесе ярдәмчесе | 20 174,00 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 20 174,00 |
| Сектор мөдире | 18 652,00 |
| Баш белгеч | 17 891,00 |
| Әйдәп баручы белгеч | 16 622,00 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 12 688,00»; |

4) **3 нче Кушымта** таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ**

| | Вазыйфаларның исеме | Хезмәт хакы | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| 1. | Башкарма комитет Җитәкчесе | 20 682,00 | | |
| 2. | Башкарма комитет секретаре | | | 16 875,00». |

**5) 7 нче кушымтада** «Муниципаль район муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру күләмнәрен һәм тәртибен»дә «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров